**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 27 апрель № 253

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында транспорт чараларын газ-мотор ягулыгына күчерүне гамәлгә ашырган юридик затларга, индивидуаль эшмәкәрләргә һәм физик затларга чыгымнарының бер өлешен каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2016 ел, 12 февраль, 90 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында транспорт чараларын газ-мотор ягулыгына күчерүне гамәлгә ашырган юридик затларга, индивидуаль эшмәкәрләргә һәм физик затларга чыгымнарының бер өлешен каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2016 ел, 12 февраль, 90 нчы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

карарның исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Транспорт чараларын газ-мотор ягулыгына (метанга) күчергәндә алынып бетмәгән керемнәрне каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында»;

1 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Бу карарга теркәлгән Транспорт чараларын газ-мотор ягулыгына (метанга) күчергәндә алынып бетмәгән керемнәрне каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен расларга.»;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасында транспорт чараларын газ-мотор ягулыгына күчерүне гамәлгә ашырган юридик затларга,

индвидуаль эшмәкәрләргә һәм физик затларга чыгымнарының бер өлешен каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен яңа редакциядә бәян итәргә (карарга теркәлә).

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2016\253.doc

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 12 февраль, 90 нчы карары белән расланды
(Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 27 апрель, 253 нче карары редакциясендә)

Транспорт чараларын газ-мотор ягулыгына (метанга) күчергәндә
алынып бетмәгән керемнәрне каплау өчен
Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибе

1. Әлеге Тәртип транспорт чараларын газ-мотор ягулыгына (метанга) күчергәндә автомобильләрне яңадан җиһазландыру һәм техник хезмәт күрсәтү пунктларының (алга таба – Яңадан җиһазландыру пунктлары) алынып бетмәгән керемнәрен каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр (алга таба – субсидияләр) бирү кагыйдәләрен һәм шартларын билгели.

2. Субсидияләр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2013 – 2023 елларга Татарстан Республикасында газ-мотор ягулыгы базарын үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 26 апрель, 283 нче карары белән расланган «2013 – 2023 елларга Татарстан Республикасында газ-мотор ягулыгы базарын үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасы чарасын тормышка ашыру максатларында, 2016 елга Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына җиткерелгән бюджет ассигнованиеләре һәм бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә бирелә.

3. Әлеге Тәртиптә файдаланыла торган төп төшенчәләр:

Вәкаләтле орган – субсидия бирү өчен каралган бюджет акчасы белән баш эш итүче Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы;

Вәкаләтле учреждение – үзенең эшчәнлеген Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының эшмәкәрлеккә булышлык күрсәтү үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе тибын үзгәртү юлы белән «Татарстан Республикасының кече һәм урта эшмәкәрлеккә булышлык күрсәтү һәм аны үстерү программаларын тормышка ашыру үзәге» дәүләт казна учреждениесен оештыру турында» 2015 ел, 4 март, 132 нче карары нигезендә гамәлгә ашыручы «Татарстан Республикасының кече һәм урта эшмәкәрлеккә булышлык күрсәтү һәм аны үстерү программаларын тормышка ашыру үзәге» дәүләт казна учреждениесе;

Яңадан җиһазландыру пунктлары – транспорт чараларын газ-мотор ягулыгына (метанга) күчерүне (алга таба – ТЧ яңадан җиһазландыру) гамәлгә ашыручы һәм түбәндәге таләпләргә туры килүче юридик затлар һәм индивидуаль эшмәкәрләр:

Татарстан Республикасы территориясендә теркәлгән булу һәм эшчәнлеген гамәлгә ашыру;

газ-мотор ягулыгы базарын үстерүне стимуллаштыру программаларын тормышка ашыруда катнаша торган җаваплылыгы чикләнгән «Газпром газ-мотор ягулыгы» җәмгыяте белән төзелгән партнерлык килешүе (алга таба – партнерлык килешүе) булу;

Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына мәҗбүри түләүләр буенча кредиторлык бурычлары булмау;

элегрәк бирелгән бюджет акчасыннан максатка ярашсыз һәм (яки) нәтиҗәсез файдалану фактлары булмау;

Субсидия алучы – аңа карата субсидия бирү турында карар кабул ителгән Яңадан җиһазландыру пункты;

Килешү – аңа карата субсидия бирү турында карар кабул ителгән Яңадан җиһазландыру пункты һәм Вәкаләтле учреждение арасында төзелә торган субсидия бирү турында килешү.

4. Яңадан җиһазландыру пунктының әлеге Тәртиптә билгеләнгән таләпләргә туры килүе түбәндәге документлар нигезендә билгеләнә:

а) гамәлгә кую документлары күчермәләре;

б) дәүләт теркәвенә алу турында шаһәдатнамә күчермәсе;

в) салым органында исәпкә кую турында шаһәдатнамә күчермәсе;

г) Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан яки Индивидуаль эшмәкәрләрнең бердәм дәүләт реестрыннан өземтә күчермәсе;

д) партнерлык килешүе күчермәсе;

е) Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләнергә тиешле салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр түләү буенча үтәлмәгән йөкләмә булмауны раслый торган һәм заявка тапшырган айга кадәр килә торган айның бер көне хәленә карата бирелгән салым органыннан белешмә;

ж) эшмәкәрлек субъектының Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә мәҗбүри пенсия һәм медицина иминиятенә иминият кертемнәрен түләү буенча үтәлмәгән йөкләмәсе булмауны раслый торган һәм заявка тапшырган айга кадәр килә торган айның бер көне хәленә карата бирелгән белешмә.

Вәкаләтле учреждение әлеге документларны ведомствоара хезмәттәшлек тәртибендә ала («а» һәм «д» пунктчаларында күрсәтелгән документлардан тыш).

Яңадан җиһазландыру пункты Вәкаләтле учреждениегә әлеге пунктта күрсәтелгән документлар күчермәсен үз инициативасы буенча бирергә хокуклы.

5. Вәкаләтле учреждение кертелгән документларны Яңадан җиһазландыру пунктының әлеге Тәртиптә билгеләнгән таләпләргә туры килү-килмәү предметына тикшерә һәм Вәкаләтле учреждениегә кертелгән көннән соң эш көннәрендә исәпләнә торган җиде көн эчендә тикшерү нәтиҗәсе турында аңа хәбәр итә.

6. Яңадан җиһазландыру пункты әлеге Тәртиптә билгеләнгән таләпләргә туры килгән очракта, Вәкаләтле орган һәм Яңадан җиһазландыру пункты әлеге Тәртипнең 4 нче пунктында күрсәтелгән документлар кертелгән көннән соң календарь көннәрендә исәпләнә торган 30 көн эчендә Вәкаләтле орган раслаган форма буенча Хезмәттәшлек турында шартнамә төзи.

7. Субсидия тиешле базар катнашучыларының коммерция тәкъдимнәрен җыю юлы белән уртача базар кыйммәтенә үткәрелә торган анализ нигезендә Вәкаләтле орган тарафыннан квартал саен билгеләнә торган ТЧ яңадан җиһазландыруның максималь кыйммәтеннән 30 процент күләмендә, әмма әлеге Тәртипкә теркәлгән кушымта буенча бер транспорт чарасына субсидиянең иң чик күләменнән арттырмыйча бирелә.

8. Субсидияләр Хезмәттәшлек турында шартнамә төзегән Яңадан җиһазландыру пунктларына түбәндәге шартларны үтәгәндә бирелә:

а) ТЧ яңадан җиһазландыру 2016 елның 1 мартыннан да иртә булмаган вакытта гамәлгә ашырылса һәм аның буенча субсидия бирелгән булмаса;

б) транспорт чарасы хуҗасы, аннан файдаланучы Татарстан Республикасы территориясендә теркәлгән булса (транспорт чарасы хуҗасы булган лизинг бирүчедән тыш);

в) куелган баллонлы газ җайланмасы элегрәк файдаланылган булмаса.

9. Гозернамәләрне (заявкаларны) кабул итү чоры Вәкаләтле орган карары белән билгеләнә. Әлеге Тәртип, аларны бу Тәртип нигезендә тутыру кирәк булган документлар формалары, шулай ук гозернамәләрне кабул итү чоры турында мәгълүмат Вәкаләтле органның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында гозернамәләрне кабул итә башлаган көнгә кадәр эш көннәрендә исәпләнә торган өч көн эчендә урнаштырыла.

Әлеге Тәртипнең 2 нче пунктында күрсәтелгән, бүленгән бюджет асиигнованиеләре тулысынча бирелгән очракта, Вәкаләтле учреждение тарафыннан гозернамәләрне кабул итү туктатыла. Моның турында мәгълүмат Вәкаләтле органның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында Вәкаләтле учреждениенең тиешле карарын раслаган көннән эш көннәрендә исәпләнә торган өч көн эчендә урнаштырыла.

10. Субсидия алу өчен Яңадан җиһазландыру пункты Вәкаләтле учреждениегә түбәндәге документлардан торган гозернамә кертә:

а) Вәкаләтле орган раслаган форма буенча гариза;

б) транспорт чарасы хуҗасының, аннан файдаланучының Россия Федерациясе гражданы паспорты (Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан яки Индивидуаль эшмәкәрләрнең бердәм дәүләт реестрыннан өземтә) күчермәсе, шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык күчермәсен теркәп;

в) транспорт чарасын теркәү турында шаһәдатнамә күчермәсе;

г) баллонлы газ җайланмасын сатуны һәм транспорт чарасына куюны күздә тоткан ТЧ яңадан җиһазландыру турында шартнамә күчермәсе, барлык өстәмә килешүләрне теркәп;

д) башкарылган эшләр акты һәм ТЧ яңадан җиһазландыру турындагы шартнамә буенча түләү хакында документ күчермәсе;

е) финанс-икътисадый нигезләмәне теркәп, субсидия күләмен исәпләү;

ж) юл хәрәкәте иминлеге өлкәсендә дәүләт идарәсе органы тарафыннан бирелгән, транспорт чарасы конструкциясенә үзгәрешләр кертергә рөхсәт бирә торган документ күчермәсе;

з) Таможня берлеге комиссиясенең «Тәгәрмәчле транспорт чаралары куркынычсызлыгы турында» Таможня берлегенең техник регламентын кабул итү

хакында» 2011 ел, 9 декабрь, 877 нче карары белән расланган «Тәгәрмәчле транспорт чаралары куркынычсызлыгы турында» Таможня берлегенең техник регламенты таләпләре нигезендә бирелгән, транспорт чарасы конструкциясенә үзгәрешләр кертү мөмкинлеге һәм тәртибе хакында транспорт чарасы конструкциясенә беренчел техник экспертиза бәяләмәсе күчермәсе;

и) лизинг шартнамәсе күчермәсе (транспорт чарасы хуҗасы лизинг бирүче булса);

к) транспорт чарасы арендасы шартнамәсе күчермәсе (булган очракта).

11. Барлык документлар кәгазьдә тапшырыла. Гозернамә кәгазьдә тапшырыла.

12. Тапшырыла торган документлар аңлаешлы итеп бастырып чыгарылган һәм бөтен пунктлар буенча тутырылган булырга тиеш (мәгълүматлар булмаганда сызык куела). Яңадан җиһазландыру пунктының мөһере белән расланган (мөһере булган очракта) һәм вәкаләтле зат имзасы белән таныкланган (юридик затлар өчен) яки үз имзасы белән таныкланган (индивидуаль эшмәкәрләр өчен) төзәтүләрдән тыш, бозып төзәтүләр һәм төзәтүләр рөхсәт ителми. Гозернамәнең барлык битләренә бит саннары куелган булырга тиеш. Документлар күчермәләре Яңадан җиһазландыру пунктының мөһере (мөһере булган очракта) белән расланган һәм шуңа вәкаләтле зат имзасы (юридик затлар өчен) яки үз имзасы белән таныкланган (индивидуаль эшмәкәрләр өчен) булырга тиеш. Гозернамә беркетелгән, гозернамәнең икенче ягында битләрнең гомуми санын күрсәтеп, Яңадан җиһазландыру пунктының мөһере (мөһере булган очракта) белән расланган һәм шуңа вәкаләтле зат имзасы (юридик затлар өчен) яки үз имзасы белән таныкланган (индивидуаль эшмәкәрләр өчен) булырга тиеш. Гозернамәне әзерләү буенча барлык чыгымнарны Яңадан җиһазландыру пункты күтәрә.

Яңадан җиһазландыру пункты тапшырыла торган мәгълүматларның дөреслеге өчен Россия Федерациясе законнары нигезендә җавап тота.

13. Документларны тапшырмау, документларны тутыру таләпләрен бозу яки кертелә торган документларда бу Тәртиптә каралган мәгълүматлар булмау субсидия бирүдән баш тарту өчен нигез булып торалар.

14. Субсидияләр алуга гозернамәләр кертелгән көнне Вәкаләтле учреждение тарафыннан гозернамәләрне теркәү журналында теркәлә.

Гозернамәләр журналда теркәлгән көннән соң эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә Вәкаләтле учреждение аларны әлеге Тәртип таләпләренә туры килү-килмәвенә тикшерә һәм Гозернамәләрнең күрсәтелгән таләпләргә туры килүе яки туры килмәве турында карар чыгара.

Вәкаләтле учреждение әлеге пунктның беренче абзацында күрсәтелгән тикшерү вакыты чыккан көннән эш көннәрендә исәпләнә торган өч көн эчендә гозернамәнетикшерү нәтиҗәләре турында Субидия алучыга хәбәр итә.

15. Гозернамә әлеге Тәртип таләпләренә туры килмәгән очракта, Субсидия алучы тапшырган документларын Вәкаләтле учреждениедән соратып алырга, шулай ук гозернамәне яңадан кертергә хокуклы.

16. Гозернамәнең әлеге Тәртиптә каралган таләпләргә туры килүе яки килмәве турында кабул ителгән карар нәтиҗәләре буенча, гозернамәнең таләпләргә туры килүе яки туры килмәве хакында карар кабул иткән көннән соң эш көннәрендә

исәпләнә торган өч көн эчендә Вәкаләтле орган субсидия бирү турында яки субсидия бирүдән баш тарту турында карар кабул итә.

17. Уңай карар кабул ителгән очракта, Вәкаләтле учреждение һәм Яңадан җиһазландыру пункты карар кабул иткән көннән соң календарь көннәрендә исәпләнә торган 30 көн эчендә Вәкаләтле орган раслаган форма буенча Килешү төзиләр.

Субсидия алучы Килешүгә кул куймаса, субсидия бирү турында карар гамәлдән чыккан дип санала.

Субсидия бирү турындагы карарны гамәлдән чыгару Вәкаләтле орган карары нигезендә гамәлгә ашырыла.

18. Килешү субсидия бирү өчен нигез булып тора. Килешүдә субсидиянең күләме, максатчан билгеләнеше, хисап финанс елында файдаланылмый калган субсидияне субсидия алучы тарафыннан агымдагы финанс елында кире кайтару очраклары, Субсидия алучының субсидия бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәвенә Вәкаләтле орган һәм дәүләт финанс тикшерүе органнары тарафыннан тикшерүләр үткәрүгә Субсидия алучының ризалыгы күздә тотыла.

19. Субсидияләр Килешү төзегән көннән соң эш көннәрендә исәпләнә торган биш көн эчендә Вәкаләтле учреждениенең казначылык органнарында ачылган шәхси счетыннан Субсидия алучының россия кредит оешмасында ачылган хисап счетына акча күчерү юлы белән бирелә

20. Субсидия алучының дөреслеккә туры килмәгән мәгълүматлар тапшыруы билгеле булган очракта, Субсидия алучы Вәкаләтле учреждениенең тиешле таләбен алган көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә бирелгән субсидияләр Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылырга тиеш.

21. Килешүләрдә күздә тотылган очракларда, хисап финанс елында файдаланылмый калган субсидияләр хисап елыннан соң килә торган елның 1 февраленә кадәр Татарстан Республикасы бюджеты кеременә кире кайтарылырга тиеш.

22. Әлеге Тәртипнең 21 һәм 22 нче пунктларында билгеләнгән вакытларны бозган очракта, Субсидия алучыдан субсидия акчасын кайтарту өчен Вәкаләтле орган әлеге Тәртипнең 21 һәм 22 нче пунктларында билгеләнгән вакытлар чыккан көннән календарь көннәрендә исәпләнә торган 30 көн эчендә субсидияне Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару буенча Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә чаралар күрә.

23. Россия Федерациясе законнары нигезендә Вәкаләтле орган һәм дәүләт финанс тикшерүе органнары Субсидия алучыларның субсидияләр бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәүләрен тикшерүне гамәлгә ашыра.

Транспорт чараларын газ-мотор ягулыгына (метанга) күчергәндә алынып бетмәгән керемнәрне каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә кушымта

Бер транспорт чарасына субсидиянең иң чик күләмнәре

| Т/с | Трасноспорт чаралары төрләре | | Бер транспорт чарасына субсидиянең иң чик күләмнәре, сум |
|---|---|---|---|
| 1 | Җиңел автомобиль | | 27 000,0 |
| 2 | Җиңел йөк (кече коммерция) транспорты | | 48 000,0 |
| 3 | Автобус | 8 метрга кадәр озынлыкта | 63 000,0 |
| 4 | | 8 метрдан күбрәк озынлыкта | 111 000,0 |
| 5 | Йөк автомобиле | | 114 000,0 |
| 6 | Магистраль тягач | | 147 000,0 |
| 7 | Трактор | 150 ат көченә кадәр егәрлектә | 80 000,0 |
| 8 | | 150 дән 350 ат көченә кадәр егәрлектә | 170 000,0 |
| 9 | | 350 ат көченнән артыграк егәрлектә | 210 000,0 |